РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«26» июля 2021 ел          Олы Кайбыч ав.          № 60

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль учреждениеләре төрен үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 13 апрелендәге 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.1.1 пунктчасы өстәргә:

«1.1.1. Башкарма комитетның рәсми исеме - «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, кыскартылган исеме - «Кайбыч районы Башкарма комитеты».».

1. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Айзатуллова Р.Г.га йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы

А. И. Рәхмәтуллин